РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
Татарско-Шуганского сельского
поселения Азнакаевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай
муниципаль районы Татар Шуган
авыл җирлеге Советы
БАШЛЫГЫ

ул. Советская, д. 41в , село Татарский Шуган,
Азнакаевского муниципального района,
423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

Совет урамы, 41в, Татар Шуган авылы
Азнакай муниципаль районы, 423327
Тел. (факс) (85592) 36-1-41
Tshug .Azn @tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«28» октября 2019 ел №2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең Татар Шуган торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Татар Шуган авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 08 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы буенча 1 йорттан 42 йортка кадэр, 44,46,48,50 йортлар, Тукай урамы буенча 1 йорттан 45 йортка кадәр, Яна урамы буенча 1 йорттан 9 йортка кадәр, Ленин урамы буенча 1 йорттан 31 йортка кадәр, Яшьләр урамы буенча 1 йорттан 12 йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Татар Шуган авылында теркәлгән һәм сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2019 елның 08 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын билгеләргә: Совет урамы буенча 43,45,47,49 йортлар, 51 йорттан 90 йортка кадэр, Җәлил урамы буенча 1 йорттан 10 йортка кадәр, һ. Такташ урамы буенча 1 йорттан 22 йортка кадәр, Сәйдәшев урамы буенча 1 йорттан 25 йортка кадәр, Сөембикә урамы буенча 1 йорттан 2 йортка кадәр

3.Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Татар Шуган авыл җирлегендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этабын уздыру вакыты – 08 ноябрь 2019 ел 10.00 сәг.тән 11.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының икенче этабын уздыру вакыты – 08 ноябрь 2019 ел 13.00 сәг.тән 14.00 сәг.кадәр;

- гражданнар җыенының беренче һәм икенче этабын уздыру урыны – Татар Шуган авылы, Совет ур. , 41б йорт, Татар Шуган авыл мәдәният йорты залы;

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 02 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә: Татар Шуган авылы, Совет урамы, 41в йорты

- сайлау хокукына ия булган Татар Шуган торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләү;

- Татар Шуган торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнарның җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

5. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2020 Татар Шуган авыл җирлеге Татар Шуган торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә, 2 торкем инвалидлардан, түләүне киметеп, аны 150 сум (50%) күләмендә билгеләп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Татар Шуган авылында Совет, Х.Такташ, Яна урамнарнын юлларына щебенка җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

- Татар Шуган авылында урамнарны яктырту, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, энергияне саклый торган лампаларны урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;

- Татар Шуган авылында җәй көне территорияне чабу;

- Татар Шуган авылында коры агачларны, куакларны кисү;

- Татар Шуган авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау (материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

- Татар Шуган авылында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен ремонтлау (коймалар урнаштыру, буяу, агарту, эшләр өчен килешү буенча түләү);

-Татар Шуганы авылында «Халыкара өлкәннәр көне», «Сабантуй» бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру;

- Татар Шуган авылында урам күрсәткечләрен ике телдә ясау һәм урнаштыру.

« РИЗА» «КАРШЫ».

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Татар Шуган авылы, Ленин ур., 26 йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

7. Әлеге карар ул халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык Г.З.Мияссарова